**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 декабрендәге 5316 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 4 августындагы 3000 номерлы карары белән расланган Новоселье урамындагы «Нокса авышлыгы» территориясен планлаштыру проектына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 августындагы 3592 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 4 августындагы 3000 номерлы карары белән расланган «Нокса авышлыгы» территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр әзерләү турында»гы карарын исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 4 августындагы 3000 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 октябрендәге 4362 номерлы, 2017 елның 15 декабрендәге 5237 номерлы, 2021 елның 15 октябрендәге 2673 номерлы, 2022 елның 4 октябрендәге 3392 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 1218 номерлы, 2024 елның 27 апрелендәге 1671 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Новоселье урамындагы «Нокса авышлыгы» территориясен планлаштыру проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешен раслау юлы белән, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 декабрендәге
5316 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 4 августындагы 3000 номерлы карары белән расланган Новоселье урамындагы «Нокса авышлыгы» территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәреш**

Төбәк һәм җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән территориядәге төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, «Нокса авышлыгы» территориясен үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турындагы нигезләмәнең 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.2 пункт өстәргә:

«1.2. Гамәлдәге җир кишәрлекләре саны – 3, шул исәптән 16:50:150401:87 кадастр номерлы, 400 кв.метрдан артык мәйданлы җир кишәрлеге, 16:50:150401:395, 16:50:150401:396 кадастр номерлы, һәркайсы 200 кв.метрдан артык мәйданлы җир кишәрлекләре».

_________________